КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 31 май г.Казань № 411

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 12 февраль, 38 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 12 февраль, 38 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 27 июнь, 515 нче; 2012 ел, 9 февраль, 93 нче; 2012 ел, 31 август, 746 нчы; 2013 ел, 14 март, 160 нчы; 2013 ел, 29 август, 611 нче; 2014 ел, 28 март, 194 нче; 2014 ел, 7 июнь, 388 нче; 2014 ел, 30 август, 630 нчы; 2015 ел, 21 октябрь, 789 нчы; 2015 ел, 29 декабрь, 1001 нче; 2016 ел, 7 октябрь, 725 нче; 2017 ел, 15 август, 581 нче; 2017 ел, 7 декабрь, 953 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.2 пунктта:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«инвестиция эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу (01.10);»;

алтынчы абзац үз көчен югалткан дип санарга;

уникенче абзацта «(01.02)» саннарын «(01.02.1)» саннарына алыштырырга;

унсигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы белән – төбәк һәм муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү функциясен гамәлгә ашырганда (03.03.01);»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты белән – архив эше белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.15.03);

Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты белән – товарларга (эшләргә, хезмәт күрсәтүләргә) бәяләрне (тарифларны, өстәмәләрне, өстәмә хакларны һ.б.) билгеләнгән тәртиптә җайга салу функциясен гамәлгә ашырганда (01.09.01).»;

3.3 нче пунктта:

3.3.1 нче пунктчада:

дүртенче абзацта «арендага» сүзеннән соң «(шул исәптән тиешле торгларны оештыру һәм үткәрү)» сүзләрен өстәргә, «аукционнарны» сүзен «торгларны» сүзенә алыштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Россия Федерациясе Урман кодексының $98^{1}$ статьясындагы 3 өлештә каралган мәгълүматны урман кишәрлекләрен арендага алучы һәм урман үсентеләрен сатып алучы намуссыз затлар реестрын алып баруга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органына түбәндәге очракта җибәрә:

урман кишәрлекләрен арендалау шартнамәләрен һәм урман үсентеләрен сатып алу-сату шартнамәләрен өзгән очракта – бу шартнамәләрне өзгән көннән өч эш көне эчендә;

дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге урман кишәрлеген арендалау шартнамәсен төзүдән яки урман үсентеләрен сатып алу-сату шартнамәсен төзүдән качырга тырышкан очракта – Россия Федерациясе Урман кодексының 79 статьясындагы 11 өлештә, $80^{2}$ статьясындагы 14 өлештә күрсәтелгән вакыт чыкканнан соң өч эш көне эчендә.»;

$3.3.1^{1}$ нче пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«составы һәм эчтәлеге вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә торган урманнар турындагы мәгълүматны Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыра.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин